**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пунктында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

2022 елның 20 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлеге Федотовка торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлеге Федотовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар; сугыш хәрәкәтләре ветераннары; Бөек Ватан сугышыһәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннары; көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә кертергә:

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру

- МТЗ-82.1 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материалларын сатып алу, асылмалы ротор чапкыч сатып алу)

- шартнамә буенча тракторчы хезмәтләре өчен түләү ( территорияне корычүп үләннәреннән чабу, кардан чистарту, полосаларны минеральләштерү һәм сөрү һәм башка эш төрләре)

2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге

- вак таш җәелгән Югары, Нагорная, Озерная, Түбән урамнарына (вак таш сатып алу һәм ташу) юллардагы чокырларны ремонтлау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет урамы, 6 йорт, Совет урамы, 8 йорт (мәдәният йорты бинасы), Кузьминовка авылы, Кооператив урамы, 10 йорт (клуб бинасы) адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/)кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Федотовка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы В.И.Павлова